ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫАЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 10.03.2026 360/1 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының район звеносы турында» 2021 елның 11 июнендәге 768 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 июнендәге 768 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының район звеносы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз компетенциясе чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнар оборонасын тәэмин итү, шулай ук торак йортларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын, социаль өлкә объектларын, җитештерү һәм инженерлык инфраструктурасын торгызу һәм төзү, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зарарланган һәм җимерелгән мәсьәләләрне карый һәм билгеләнгән тәртиптә Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тиешле тәкъдимнәр кертә;».

1.2. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алабуга муниципаль районының норматив хокукый актларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә,

шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә башка норматив документларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;».

1.3. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 4 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алабуга муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр фаразларын карый, гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм бетерүгә, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны эшләүне, гамәлгә ашыруны оештыра һәм шулай ук гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итә;».

1.4. 3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«гражданнар оборонасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли.».

2. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче — Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 2AE1AA8E107BD0A6911BA308E44A8D0A
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 28.01.2025 до 23.04.2026

Лист согласования к документу № 360/1 от 10.03.2026
Инициатор согласования: Половинкина И.А. Главный специалист
Согласование инициировано: 12.03.2026 14:51

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>12.03.2026 - 15:24 | - |